ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

___04.08.2026______________ **г.Чистополь** **№** ___327_____________

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгару турында» 2021 елның 30 июлендәге 428 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хокукый актны Россия Федерациясе законнарындагы үзгәрешләргә туры китерү максатларында, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 333.33 һәм 333.35 маддәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 25 маендагы 142-ФЗ номерлы Федераль закон, «Реклама турында» Федераль законның 19 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында 2022 елның 16 апрелендәге 106-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 428 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең карар белән расланган административ регламентында (алга таба-Административ регламент):
1.1.1. Административ регламентның 2.9.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.9.1. Дәүләт пошлинасы Россия Федерациясе Салым кодексының 333.33 маддәсендәге 1 өлешенең 105 пунктында түбәндәге күләмдә каралган:
- реклама конструкциясен урнаштыруга рөхсәт биргән өчен - 10000 сум.
Дәүләт пошлинасы гариза биргәнче мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләнә.».
1.1.2. Административ регламентның 2.8.2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәте 38-ФЗ номерлы Федераль

законның 19 маддәсендәге 5.1, 5.6, 5.7 өлешләрендә кулланылган очракта, 5 өлешендә билгеләнгән таләпләрне бозу;».
1.1.3. Административ регламентның 2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр.
Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 1 өлеше нигезендә җирле үзидарә вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән раслана.
Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.».
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/ урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э. Р. Хәсәнов